Нурмөхәммәтова Р.С.
Казан

# Г.Ибраһимов әсәрләрендә ризык атамалары

(Мәкалә 11-14-16029а/В номерлы РГНФ гранты кысаларында язылды)

Г.Ибраһимов үзеннән соң зур мирас калдырып киткән шәхес. Әдипнең әсәрләре әдәбият белгечләренең игътибарын үзенә күптәннән җәлеп итүе табигый: аның иҗатын өйрәнүгә күп кенә галимнәр өлеш керткән, шактый фәнни хезмәтләр язылган.

Г.Ибраһимов әсәрләре тел белгечләренең тикшеренүләре өчен дә бай материал бирә, шунлыктан телчеләрнең дә аның иҗатына әледән-әле әйләнеп кайтуы гаҗәп хәл түгел. Соңгы елларда тел белемендә барлыкка килгән һәм бүгенге көндә инде шактый уңышларга ирешкән лингвокультурология фәне өчен дә Г.Ибраһимов әсәрләре кызыклы тикшеренү объектын тәшкил итә. Бу нисбәттән әлеге әсәрләрдә кулланылган ризык атамаларын барлау гыйбрәтле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Һәрбер язучы үзе яшәгән чорны тасвирлый, шунлыктан әсәр тукымасына шул чорның колоритын, ул вакыттагы тәртипләрне, халыкның яшәү рәвешен, матди хәлен, рухи дөньясын ачык чагылдырган күренешләрнең, предметларның, вакыйгаларның кереп китүе гайре табигый саналмый. Г.Ибраһимов әсәрләрендә дә ул яшәгән заманның матди мәдәният лексикасы зур урын алып тора: халыкның көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, яңа җәмгыять алып килгән үзгәрешләрне, яңача хуҗалык тәртибен һ.б. сурәтләгәндә ул телнең лексик байлыгын бөтен тулылыгы белән файдалана.

Ашау, ризык темасы теләсә кайсы тарихи үсеш этабында һәркем өчен актуаль тема санала, чөнки ул кешенең беренчел биологик ихтыяҗларын тәшкил итә. Шулай булуга карамастан, Г.Ибраһимов әсәрләрендә бу тематик төркемгә караган лексиканы артык күпсанлы дип әйтеп булмый. Бу аңлашыла да. XX йөз башы – әдипнең актив иҗат иткән чоры Россия халкы өчен дә, татарлар өчен дә сынауларга шактый бай була. Ашау-эчү әйберләренең байлыгы күзлегеннән караганда да бу искиткеч авыр еллар: сугышлар,

революцияләр, ачлык, җимереклек... Мондый шартларда ризык төрлелеге турында фикер йөртү мөмкин дә түгел. Димәк, Г.Ибраһимов, реалист-язучы буларак, моңа күз йома алмаган һәм аның әсәрләрендә ашамлык-эчемлек атамаларына ярлылык үзен аклый да. Язучы әсәрләрендә ризык атамаларының күп булмауның сәбәбе тирәнрәк тә яшеренгән булырга мөмкин. Ач халыкка хыялдагы нигъмәтләр, сыйлар турында язу миһербансызлык, рәхимсезлек булыр иде. Шуңа күрә ул бу тематикага караган сүзләрдән аңлы рәвештә баш тарткандыр, аларны текстны матурлау, чынбарлыкның дөреслеген күрсәтү өчен генә берникадәр күләмдә куллануны кирәк тапкандыр.

Г.Ибраһимовның “Казакъ кызы”, “Кызыл чәчәкләр”, “Тирән тамырлар” әсәрләрендә очраган ризык атамаларын барлап чыкканнан соң, аларны түбәндәге семантик төркемнәргә бүлеп карадык.

1. Азык-төлекне гомумиләштереп атаучы сүзләр: *аш, аш-су, нигъмәт, ризык, сый.* ***Аш*** сүзен Г.Ибраһимов гомумән ризык, ашау вакыты мәгънәләрендә куллана: Шуны ишеткәч, ашаганым *аш*, эчкәнем су булмады... (Кызыл чәчәкләр). Көндезге *аш*ка таралып, кичке алтыда яңадан хөкем ачылгач, гаепләнүчеләрнең актык сүзләре башланды (Тирән тамырлар).

***Аш-су*** табынга куюю өчен хәзерләнгән ашамлык, сыйны белдерә: Яңа күрше Гайнияләр *аш-су* белән ярдәм иттеләр (Кызыл чәчәкләр). Бергә гомер иткән, яхшылыгын, яманлыгын бергә кичергән, бергә *аш-су* күргән кешеләр онытыламыни? (Тирән тамырлар).

***Сый*** – кунаклар чакырылганда, бәйрәмнәрдә әзерләнә торган затлырак ашамлык-эчемлек (2, 491): Ике коданың катнашы күп, *сый*лары уртак, уен-көлкеләре бергә бара (Казакъ кызы).

***Нигъмәт*** һәм ***ризык*** – һәртөрле ашамлык, ризыклар җыелмасы: Ара-тирә байның кымызын эчәм, итен ашыйм икән – казакъ йорты үзенең бу *нигъмәт*ләрен далада каңгырып йөргән бичара нугай хәерчегә дә бирә түгелме?! (Казакъ кызы) Үз бәхетеңне ашавың җитмәгән, инде минем балаларым *ризыг*ына тотынгансың икән!» — дип каһәрләп, мич буендагы

кайчыны алып, Шаһбаз башына бәрә (Кызыл чәчәкләр). Ашыйсы *ризыгы* бетмәс, башы исән булса, адәм баласы бер кайта икән... (Казакъ кызы).

2. Итле ризык атамалары: *бөер, бөйрәк, җылкы казылыгы, ит, кабырга, казылык, куй башы, куырдак, тукты, ял*. ***Казылык*** – атның түш ите; эчәккә яки ясалма элпәгә тутырылып махсус эшләнгән ит фаршы (2, 222). Бу сүзнең “Казакъ кызы” әсәрендә аңлатмалы сүзлеккә теркәлгән ике мәгънәсе дә күзәтелә: Таныш булмасалар да, хөрмәтләп каршы алдылар, хуҗаның янына утыртып, туктының симезе, *җылкы казылыгы*ның майлысы белән кунак кылдылар (монда атның түш ите булырга мөмкин – Н.Р.). Туктының симезен суйдырып, *казылык*ның, *ял*ның майлысын салсаң кирәк, – диде. Йортта кунак булгач, ит пешкәндер, *тукты*дан, *казылык*тан бер согынып килим, дип уйлады (соңгы мисалларда эчәккә тутырылган итне аңлатауы мөмкин – Н.Р.). Әлеге мисалларда очраган *ял* һәм *тукты* сүзләренә дә тукталып китү урынлы булыр. Бу сүзләр “Казакъ кызы” әсәрендә еш очрый. Казах милли ризык атамасы буларак, “жал” ат муенының яллы җиренең өске өлешендәрәк тире астындагы майлы озынча кисәген аңлата, һәм ул хайванның эчке әгъзалары арасында иң затлысы санала икән (1). Контекст буенча ***ял***ның шуңа туры килүен аңлыйбыз. ***Тукты*** – тууына алты айдан артыграк вакыт узган куй (сарык) бәрәне, безнең мисалда ул әлеге бәрәннең ите мәгънәсендә килгән.

“Казакъ кызы” әсәрендә ***ит*** сүзе дә күп очрый, чөнки далаларда яшәү рәвеше күчмә терлекчелек белән шөгыльләнер өчен җайлы булган, ит мондагы халыкның төп ризыгын тәшкил иткән: Казан янында азапланучы тукал табак тутырып *ит*не өлкән өйгә алып керде. Казакъның борынгы гадәте буенча, ул кунакка хөрмәт кылу тик кымыз һәм *ит* белән генә була дип карый...

3. Сөт-йомырка ризыклары: *йомырка, каймак, катык, корт, май, сөт, эремчек*. Бу сүзләрнең күбесе далада яшәүчеләрнең тормышын яктырткан “Казакъ кызы” әсәреннән табылды. Г.Ибраһимов ***йомырка*** сүзен нәкъ ризык атамасы буларак кулланмаган, контексттан күренгәнчә, ул әзер ашамлыкны аңлатмый: Куйчы карт Күчәрбай миңа үрдәк *йомырка*лары алып кайткан иде. Гөлчәчәк күз яше ара көлеп, шатланып, *йомырка*ларны алды да, кәләпүш

ертыгын бармак очы белән генә тотып, ачык ишектән далага ыргытты. Бала теге *йомырка*лар белән булган иртәнге талашын сөйли башлады (Казакъ кызы).

***Каймак*** – сөтнең өстенә җыела торган куе, майлы өлеше (2, 222): Тирмәнең сул ягында торган тәбәнәк шкафтан керле ашъяулык, сабы сынган чәйнек, ямаулы чынаяклар, берничә бавырсак салган бер тәрилкә алып, боларны кунак алдына китереп куйды, куе *каймак* салып, чәй ясый башлады. Вакыт соң булса да, килен коедан су китереп самавыр куйды, шүрлектән *каймак*, бавырсак алды, чынаяклар чыгарды (Казакъ кызы).

***Май*** – хайван сөтеннән (сөт өстен, каймакны язып) алына торган туклыклы матдә: Ятим бозау асрасаң, авызың-борының *май* итәр, ятим бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, дигән борынгылар... (Кызыл чәчәкләр) Мин әнинең хәлен сорашып бетерергә өлгерә алмадым, яшьләр каяндыр *май, йомырка, сөт*, икмәк тә табып китерделәр (Кызыл чәчәкләр).

***Эремчек, корт*** – сөттән әзерләнә торган ризык атамалары: Сарсымбайның казан янында *эремчек* кайнатып маташкан Айбалага йомшак тавыш белән: «Киленчәгем! Карлыгач-Сылуың тормаган булса кирәк, барып уятсаңчы!» – дигән сүзен ишеткәч, кызның йөрәге дерелдәп китте. Тукалның кушуы буенча, тирмәдән әле кибеп бетмәгән *корт*ларны кояшка чыгарды, элеккеләре белән янәшә өченче казанны куеп, астына тизәк ягып, берничә көн буенча җыелган сөттән *эремчек* кайната башлады (Казакъ кызы).

4. Камыр һәм ипи-күмәч ризыклары: *бавырсак, бәлеш, җәймә, икмәк, клиндер, күмәч, нан, прәннек, сохари.* ***Бавырсак*** – чикләвек зурлыгында ваклап, майда кайнатып пешерелә торган милли камыр ризыгы (2, 64): Ул <…> самавыр, чәй, *бавырсак* кебек начар бидгатьләрне эшкә санамый иде (Казакъ кызы).

***Бәлеш*** – эченә төрле ашамлыклар (ит, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б.) салып, мичтә табада пешерелгән камыр ашы (2, 102): Бер көнне шулай кечкенә *бәлеш*ләр пешергән дә ике баласына икене тоттырган Гали белән Фазыйл өйләреннән ак күмәч кисәкләре, *бәлеш* калдыклары чыгарып бирделәр (Кызыл чәчәкләр).

***Икмәк катысы*** аңлатмалы сүзлектә “икмәкнең тышындагы каты катлавы” дип бирелә (2, 178). Әсәрдә ул каткан ипи мәгънәсендә кулланылган: Юынмадым, чәй-фәлән сорап тормадым, бер сынык *икмәк катысы* белән санап куйган чылгыйларымны алдым да тышка йөгердем (Кызыл чәчәкләр).

***Сохари*** – махсус киптерелгән икмәк кисәкләре: Мин исән-сау, ди; *сохари* җибәрегез, ди; үзем балта эшенә керештем, ди (Кызыл чәчәкләр).

***Күмәч*** – май, йомырка, шикәр кушып, камыр басып пешерелгән ашамлык; ак оннан пешерелгән икмәк (2, 331): Бу вакыт теге базарчылар симез ит пешертәләрдер, *ак күмәч* ашыйлардыр, – ә безгә нәрсә? (Кызыл чәчәкләр). Кәрәзле бал белән *ак күмәч* куйды (Тирән тамырлар).

***Прәннек*** – балга, бәрәңге балына яки шикәр сиробына катырылган һәм төрле аш тәмләткечләр салып пешерелгән баллы вак күмәч (2, 556); ***клиндер*** – гадәттә төче камырдан боҗрасыман итеп пешерелгән күмәч (2, 263): Без һәммәсенә капка ачабыз; күбесе безгә ярты конфетмы, *прәннек*ме, каткан *клиндер* кисәгеме ташлап китә (Кызыл чәчәкләр).

5. Чәй ризыклары: *бал, кәрәзле бал, конфет, шикәр*. ***Бал*** – бал кортлары чәчәк нектарыннан җыеп ясаган куе, татлы, авыр сыеклык (2, 68): *Бал*-май үземдә күп була... (Кызыл чәчәкләр) ***Кәрәзле бал*** – кәрәзе белән алынган бал (2, 317): *Кәрәзле бал* белән ак күмәч куйды (Тирән тамырлар).

***Конфет*** – кечерәк шарчык, мендәрчек, озынча һ.б. формалардагы баллы-шикәрле кондитер ашамлыгы (2, 278): Аның күз төбе шешеп чыкты, күп *конфет* ашаудан черегән тешләреннән кан китте (Кызыл чәчәкләр). Арыслан аның башыннан сыйпап йөзеннән сөйде дә, кулындагы ашыкларын карап, кайдан алуын сорашып, ике *конфет* бирде (Казакъ кызы).

***Шикәр*** – чөгендер яки камышның махсус төрләреннән алына торган ак төстәге вак кристаллардан гыйбарәт татлы азык продукты (2, 683): Көндездән калган ике бәрәңгене тозлап ашыйм, сөтсез, *шикәр*сез бер чынаяк чәй эчәм дә, читән өебезнең ишегалдына чыгып, әткәйнең чикмәненә уралып, җир идәнгә йокларга ятам (Кызыл чәчәкләр).

6. Яшелчә, җиләк-җимеш: *бәрәңге, җиләк, җимеш, кавын, карбыз, кәбестә, кишер, кыяр, суган, торма, чөгендер*. Түбәндәге мисаллар барысы да “Кызыл чәчәкләр” әсәреннән алынды: Әнкәй аңа бер *бәрәңге*, бер сынык икмәк бирде, кем икәнен сорашты. Гайния җыеп кайткан *җиләк*ләр белән тәмләп чәй эчтек... Өй буенда бакча: анда *җимеш*ләр пешә... Ындырда бәрәңге бакчасы, анда *кыяр, карбыз, кавын, торма, чөгендер, кишер, кәбестә* – җаныңа ни кирәк, һәммәсе бар... Күп вакыт үтмәде, тегеннән, чаршау астыннан, Гайниякәйнең ак кулы безгә зур бер тәлинкә белән әйбәтләп киселгән икмәк, әрчеп туралган *суган*, байтак ук салкын ит сузды.

7. Ярмадан әзерләнгән ашамлыклар Г.Ибраһимовның карап үтелгән әсәрләрендә күп түгел: “Казакъ кызы” әсәрендә *кужә* сүзе очрады. Татар телендә ул киптергән бодайны киледә төеп яки башка юл белән ваклап, ваклаганнан соң казанда яки чуенда кайнатып пешерелгән сыек ботка атамасы. Ә әсәрендәге мәгънәсе берникадәр аерыла: Карт, кулына бер-ике тамчы су салып, керле сөлгегә сөртте дә, агач савыт белән бирелгән куе *кужә*не – пешереп киптерелгән тары ярмасын ашап, кечкенә күн турсыкка салынган әйрәнне алып, йортка чыкты.

8. Эчемлек исемнәре: *әйрән, кымыз, чәй, кызылбаш, аракы, сыра.* Бу атамалар арасында исерткеч һәм исерткеч булмаган эчемлекләр бар. Иң элек алкогольсез эчемлекләрне карап үтик. ***Әйрән*** – катыкны суга болгатып ясалган эчемлек (2, 745), ул сусаганда әйбәт, шуңа күрә аны күбрәк җәен әзерләгәннәр һәм салкын килеш эчкәннәр: Әбкәем, бик харап сусадым. Бозлы *әйрән*ең юкмы? (Кызыл чәчәкләр).

***Чәй***не татарлар бик күптәннән куллана башлаганнар. Кайчак чәй янына төрле ризыклар куелган һәм ул аерым ашауны алыштырган. Әсәрләрдә бу үзенчәлекләр ачык күренә: Ул кергәндә Сарсымбай түгәрәк тирмәнең түрендә *чәй* эчеп утыра иде (Казакъ кызы). Гайшә самавыры, табасы тирәсендә маташа биреп, өстәлгә *чәй* әзерли-әзерли, каланы сөйли башлады (Тирән тамырлар). Аннан соң бер чынаяк бик каты *чәй* бирәләр дә, Гыйлаҗи аны тышка, һавага алып чыгып керә (Кызыл чәчәкләр).

***Кымыз*** – бия, дөя яки кәҗә сөтеннән әчетеп ясалган эчемлек (2, 306). Кымызны казакъ һәм монгол далаларында яшәүче борынгы кабиләләр иң беренче ясый башлаган. Күчмә халыклар аны ясау технологиясен сер итеп саклаганнар. Ул казакъ, кыргыз халкында аеруча популяр эчемлек саналган. Шуңа күрә бу сүз “Казакъ кызы” әсәрендә бик күп очрый (80 чамасы): *Кымыз*ның мул чагы, туктыларның симез заманы, йөгерекләрнең дә дер кайнап йөрәк суккан вакытлары иде. Зиннәтле зур, бай тирмәнең ишеге төбеңдәге сабадагы *кымыз*ны пешкәк белән шапырып тора иде. Борынгы кодагыз гаепләп китмәсен: туктының симезен суегыз, *кымыз*ны мул китерегез, – диде. Ишек ачылды, зур чаган табак белән *кымыз* күтәреп тукал керде (Казакъ кызы).

***Аракы*** – спиртлы исерткеч эчемлек (2, 44): Аңа *аракы* дип су эчерәләр (Кызыл чәчәкләр). ***Кызылбаш*** сүзе әсәрдә шулай ук исерткечне белдерә: Менә сезгә алтын шахтасы янында ясалганнан бер *кызылбаш*! (Кызыл чәчәкләр). ***Сыра*** – арпа салатыннан ясала торган җиңелчә исерткеч эчемлек (2, 494): Кооператив тапшырган эшләреннән бушаган араларда, Җамали абзый: “Бусы *сыра*лык булыр!” – дип, иске киемнәрне ямый, өр-яңа кебек иткәнче өтели дә сатарга алып чыга иде. (Тирән тамырлар)

Г.Ибраһимов әсәрләрен тикшереп чыкканнан соң, түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин: башка матди мәдәният элементлары (кием-салым, торак һ.б.) белән чагыштырганда, аларда ризык атамалары әллә ни күп түгел. Шулай да бу сүзләр буенча әсәрләрдә сурәтләнгән чорда, төбәктә халыкның нинди ризыкларга өстенлек бирүен ачыкларга була. Бу исә этнографик, лингвокультурологик эзләнүләр өчен нигезле мәгълүмат бирә.

Әдәбият


1. Ахметова Ш.К. Пища казахов Западной Сибири: традиции и новации. – [Электронный ресурс]. - Режим доступа: kyrgyz.ru
2. ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.
3. kitap.net.ru

**Аннотация**. В своих произведениях каждый писатель отражает определенную эпоху. Для этого он использует лексику, отражающую материальную и духовную культуру народа. Лексика материальной культуры татарского языка включает такие жизненно-важные лексико-тематические группы, как жилище, одежда, еда, орудия труда и т.д. Статья посвящается изучению названий еды и напитков в произведениях Г.Ибрагимова. Исследование проводится в русле новой лингвистической науки – лингвокультурологии.

**Заявка на участие**

1. Нурмухаметова Раушания Сагдатзяновна
2. КФУ, Институт филологии и искусств
3. Доцент кафедры общей лингвистики и лингвокультурологии, кандидат филологических наук
4. Названия пищи в произведениях Г.Ибрагимова (видеоматериала нет)
5. 420126, Г.Казань, пр.Ямашева, д.51, кв. 259

rsagadat@yandex.ru

517-68-20 (дом.)

292-68-31 (раб.)